# Мәктәп хәбәрчесе

**№1**

**октябрь 2018 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

***/ Мөхәррир сүзе /***

## *Хәерле сәгатьтә!*

Кадерле балалар, хөрмәтле әти-әниләр, укытучылар һәм мәктәп хезмәткәрләре! Быелгы уку елында безнең Түбән Майна урта мәктәбе тормышында тагын бер яңа сәхифә ачылды. Директор Насыйров Рафик абый тәкъдим иткәч, укытучылар һәм укучылар белән киңәшләшеп, мәктәбебезнең газетасын чыгара башларга карар кылдык. Бу газетаны бастыру максаты – укучыларыбызның иҗади активлыгын арттыру, ата-аналарны, авыл җирлеге халкын мәктәп тормышы белән таныштыру һәм, гомумән, үзебезнең уку йортын дөньяга таныту.

Газетага **“Мәктәп хәбәрчесе”** дигән исем бирергә булдык. Чөнки бу мәгълүмат чарасында нигездә мәктәп тормышына кагылышлы хәбәрләр һәм материаллар урын алачак. Быелгы уку елында газетаны бер айлык форматта чыгарырга булдык. Газета материаллары “Мәктәп яңалыклары”, “Укучылар иҗаты”, “Күренекле шәхесләр”, “Өлкәннәр киңәше”, “Сорау - җавап”, “Чал тарихта эзлебез...”, “Күңелле тәнәфес”, “Котлыйбыз!” кебек рубрикалар да урын алачак. Эш барышында, тупланачак язмаларның үзенчәлегенә карап, башка рубрикалар да ачылыр дип уйлыйбыз.

Газетаның редколлегиясенә нигездә VII һәм VIII сыйныф укучылары сайланды. Бу хезмәт, әлбәттә, өлкән сыйныф укучыларына күбрәк туры килә. Ләкин имтиханнарга әзерләнү өчен вакытлары җитмәү сәбәпле, чыгарылыш сыйныф укучыларына өстәмә эш йөкләмәскә булдык. Редколлегия әгъзалары журналистика өлкәсендә җитәрлек тәҗрибә туплаганчы, мөхәррир вазифасын әлегә үзем башкарачакмын.

Барлык газета укучыларны да “Мәктәп хәбәрчесе”нең беренче саны чыгу белән котлыйбыз! Сездән актуаль, файдалы һәм кызыклы материаллар көтеп калабыз.

***Мөхәррир Гөлчәчәк Шәмәрданова***

***/ Мәктәп яңалыклары /***

**1 октябрь** – өлкәннәр көне, мәктәп ветераннарына бүләкләр өләшенде.
**5 октябрь** – Укытучылар бәйрәме уңаеннан мәктәптә “Үзидарә көне” уздырылды.
**8-19 октябрь** – фән олимпиадаларының мәктәп туры уздырылды.
**26, 27 октябрь** – мәктәптә Уңыш бәйрәме үткәрелде.
**30 октябрь** – беренче уку чирege тәгәлләнде.
**31 октябрь** – балалар бакчасында Уңыш бәйрәме үткәрелде.
**31 октябрь** – көзге каникуллар башланды.

## *5 октябрь – Укытучылар көне!*



Хөрмәтле укытучылар!!! Сезне һөнәри бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез! Барыгызга да исәнлек-саулык, рухи күтәренкелек, бетмәс-төкәнмәс энергия, эшегездә зур уңышлар, яңа үрләр яулавыгызны телибез! Сезнең һәр дәресегез укучыларга яңа белемнәр, зур ачышлар китерсен! Алдагы тормышыгыз сезгә һәм укучыларыгызга бары тик “бишле” билгеләре генә куйсын!

***Олы ихтирам белән Түбән Майна мәктәбе укучылары***

***/ Рәсми хәбәрләр /***

## *Беренче чирек нәтиҗәләре*

30 октябрь көнне 2018/2019 уку елының беренче чирege тәгәлләнде. Мәктәптә белем алучы 57 укучының 43 енә чирек билгеләре чыгарылды. Шулардан 18 укучы чирекне «4», «5» ле билгеләренә тәмамлады. Бер укучыбыз – икенче сыйныфтан Гафиятуллин Фаил – гел “5”ле билгеләренә генә тәгәлләде. Тулаем алганда, мәктәп буенча белем сыйфаты 46,5 % тәшкил итә.

Октябрь аенда фән олимпиадаларының мәктәп туры уздырылды. Шулар нәтиҗәсендә 11 укучыбыз 10 фәннән олимпиадаларның район турында катнашу мөмкинлеге алды.

Чирек барышында мәктәптән тыш чаралардан көзге урманга сәяхәт оештырылды. “Милли көрәш”, “Эрудит”, “Оста куллар” түгәрәкләре эшчәнлекләрен башлап җибәрде. Хезмәт юнәлеше буенча мәктәп бакчасында үстерелгән яшелчә уңышы җыеп алынды.

Көзге каникуллар 31 октябрьдә башланып, 6 ноябрьдә тәгәлләнә. 7 ноябрьдән икенче чирек башлана. Укучыларга каникул көннәрен файдалы һәм кызыклы итеп уздыруларын һәм алдагы чиректә тагын да тырышып укуларын теләп калабыз.

***Укыту эшләре буенча урынбасар Илдар Сафиуллин***

/ Чал тарихта эзле без /

## Түбән Майна урта мәктәбе тарихындагы мөһим вакыйгалар хронологиясе

- **1829 ел** – авыл мәктәбе тарихи документларда тәүге тапкыр искә алына.
- **1883 ел** – башлангыч белем бирүче мәктәп урта белем бирүче мәдрәсә буларак эшли башлый. Шул ук елны мәдрәсә өчен яңа бина төзелә.
- **1906-1907 еллар** – мәдрәсә өчен яңа бина төзелә.
- **1918 ел** – мәдрәсә беренче баскычлы совет хезмәт мәктәбе итеп үзгәртелә.
- **1963-1964 еллар** – мәктәп өчен агачтан яңа бина төзелә.
- **1965 ел** – башлангыч мәктәп базасында сигезьеллык мәктәп ачыла. Шул елдан Түбән Майнага Чуаш Майнасыннан да балалар укырга йөри башлый.
- **1966 ел** – иске мәчет бинасы сүтелеп, материалларыннан башлангыч мәктәп бинасы корыла.
- **1977 ел** – мәктәп өчен кирпечтән ашханә бинасы төзелә.
- **1978 ел** – авылда даими эшләүче балалар бакчасы ачыла.
- **1995 ел** – сигезьеллык мәктәп урта мәктәп статусы ала.
- **2011 ел** – мәктәпкә автобус тапшырыла, тирә-яктагы татар авылларыннан укучылар килеп укый башлый.
- **2014 ел** – мәктәп һәм балалар бакчасы өчен яңа бина ачыла.
- **2015 ел** – балалар бакчасы мәктәп белән берләштерелә.
- **2017 ел** – Иске Татар Әдәмсуы мәктәбе Түбән Майна мәктәбенең филиалы итеп үзгәртелә.

## 20 октябрь – Пешекчеләр көне!



Рәхмәт сезгә, пешекче апалар, бәйрәмегез котлы булсын! Киләчәктә дә безне тәмле ашларыгыз белән шатландырып эшләгез!

/ Күренекле шәхесләр /

## Гомерләрен мәктәпкә багышлаучылар

Ел саен мәктәбебездә Укытучылар көне зурлап билгеләп үтелә. Хезмәт юлларын мәктәп белән бәйләгән мөхтәрәм ветераннарга бүләкләр тапшырыла, алар өчен төрле чаралар уздырыла. Кызганычка каршы, ул хөрмәтле затларның кайберләре безнең арабызда юк инде. Шундыйлардан, иң беренче итеп, гомерләрен балалар укытуга багышлаган Хәлиулла бабай һәм Шәрифә әби Исмәгыйлевларны атау урынлы булыр.



Хәлиулла бабай һәм Шәрифә әбинең Түбән Майна башлангыч мәктәбендәге эшчәнлеге авыр сугыш елларыннан соң башланып китә. Аларга кадәр мәктәптә гел читтән килгән укытучылар гына эшләгән. Ул елларда, балалар саны кимү сәбәпле, 4 сыйныфка 1,5 ставка укытучы вазифасы гына калдырылган була. Шуңа да карамастан, Хәлиулла бабай һәм Шәрифә әби авылны ташламыйлар. Бер-берсенә терәк булып, мәктәпнең авыр йөген икәүләшеп күтәрәләр.

1950 еллар уртасыннан авылда укучы балалар саны нык арта. 4 сыйныфны тәмамлаган укучылар белем алуны Югары Майна мәктәбенә йөреп дәвам итәләр. Шул сәбәпле, авылның үзендә яңа мәктәп бинасы салып, сигезьеллык белем бирүгә күчү таләп ителә. Халиулла бабай бик күп авырлыклар күрсә дә, бу эшне башкарып чыгуга ирешә. 1960 еллар башында авыл уртасында, колхоз ярдәме белән, мәктәпнең яңа бинасы төзелә. 1965 елның 1 нче сентябреннән Түбән Майна мәктәбендә укулар сигезьеллык программа нигезендә укытыла башлый.

Хәлиулла бабай белән Шәрифә әби, 1970 еллар уртасында лаеклы ялга чыкканчы, башлангыч сыйныфларны укыталар. Озак еллар дәвамында башкарган фидакарь хезмәтләре өчен Хәлиулла бабай "Хезмәт ветераны", Шәрифә әби ТАССР Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнәләр. Олыгайган көннәрендә дә алар халыкка хезмәт итүләрен ташламыйлар – 1992-1994 елларда авылда мәчет салу белән җитәкчелек итәләр. Халиулла бабай белән Шәрифә әби соңгы көннәренә чаклы авылның киләчәге өчен янып-көеп яшәделәр. Аллаһы Тәгалә урыннарын җәннәттә кылсын.



Мәктәп эшчәнлегендә укытучылар һәм тәрбиячеләр белән беррәттән, техник хезмәткәрләрнең дә өлеше бик зур. Алар арасында мәктәп укучылары һәм бакча балалары өчен аш әзерләүче **Рәмия һәм Илсөяр апалар** аерым урын алып тора. Алар – чын мәгънәсендә үз эшләренең осталары. Без аларны һәм элек пешекче булып эшләгән **Морадимова Мөнибә һәм Гафиятуллина Әкълимә әбиләр, Гарифуллина Миңлегөл, Гобәйдуллина Гөлсинә, Сәгъдиева Рәмзия, Туктамышева Роза апаларны** да чын күңелдән һөнәри бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез.

## *Мәктәптә үзидарә көне*




Күптәннән килгән гадәт буенча, Укытучылар көне хөрмәтенә, 5 октябрь көнне мәктәптә үзидарә көне уздырылды. Өлкән сыйныф укучылары башлангыч һәм урта сыйныфларга дәрес бирде. Мәктәп директоры вазифасын Мөхәмәтҗанов Айрат башкарды. Уку көне ахырында нәтиҗәләр ясалды. Яшь мөгаллимнәр фикеренчә, дәресләргә иң яхшы әзерләнгәне 8нче сыйныф булды.

***Нәзирә Әхмәтова.***

## *Уңыш бәйрәме*

Безнең мәктәптә кабул ителгән тәртип буенча, һәр уку чиреге зур бер бәйрәм белән тәгәлләнә. Ә беренче чирек ахырын Уңыш бәйрәменнән башка күз алдына китереп тә булмый. Бу күңелле вакыйганы укучылар гына түгел, авыл җирлеге халкы да көтеп ала.

Быелгы Уңыш бәйрәмен башлангыч сыйныфлар ачып җибәрде. Алар 26 октябрь көнне ашханә залында "Сөмбелә" дигән тамаша күрсәттеләр. Көз темасына ясалган рәсемнәр һәм яшелчәләрдән эшләнгән композицияләр бәйрәмгә аеруча ямь бирде.



## *Таныш булыйк!*

Узган ай башыннан безнең мәктәптә яңа укытучы эшли башлады. Ул – Казаннан авылда яшәргә күченеп кайткан Гөлчәчәк апа. Бу газета эшен оештыру да аның вазифасында. **Без, редколлегия әгъзалары, Гөлчәчәк ападан үзен газета укучылары белән таныштыруны үтендек.**



- Мин, Шәмәрданова Гөлчәчәк Фазыл кызы, 1989 елда Казан шәһәрендә тудым. Педагогика көллиятен һәм КФУ тәмамладым. Хәзерге вакытта аспирантурада укыйм. Авылга кайтканчы 2 ел 1нче гимназиядә башлангыч сыйныфлар укыттым.

**- Гөлчәчәк апа, шәһәрдә туып-үскән кыз буларак, ни сәбәпле авылда яшәргә булдыгыз?**

- Шәһәрдәге яшәү рәвешеннән туеп, чын татар авылына яшәргә күчеп килдем. Әлбәттә, "бөтен кеше авылдан шәһәргә бара, ә син шәһәрдән авылга китәсең" дигән сүзләрне ишетермен дип шикләнми идем. Тик шәһәрдә озак вакыт яшәп, андагы "акча колы булу", "үз мәнфәгатьләреңне генә кайгырту"ны күргән кеше генә аңлар мине. Кызганыч, хәзерге көндә шәхси максатлар гына алга куела, ә җәмгыять, милләт, дин арттагы планда кала.

**- Газета укучыларга нинди теләкләр ирештерәсегез килә?**

Мәктәп укучылары белән аралашырга яратам, алар бит безнең киләчәк буыныбыз. Тик мәктәптән соң нишлисез дигәч, барысы да "Шәһәргә китәбез" – диләр. Хөрмәтле укучылар! Перспектива эзләп шәһәргә баруыгыз аңлашыла, тик бүгенге көндә шәһәр элеккеге промышленность үзәге булган шәһәр түгел шул. Элек чыннан да, шәһәргә бару илгә алга барырга булышу белән бер иде. Хәзерге көндә сәламәтлек, балалар тәрбиясе, гаилә төзеклеге ягыннан авылда тору күпкә кулайрак. Авыл мәктәбен киләчәктә күп белемле, тәрбияле шәхесләр чыгарсын, һәм без бу юлда аңа тырышлык куйыйк!

27 нче октябрь,шимбә көнне, Түбән Майна мәдәният йортында кичке тамаша - КВН узды. Өлкән сыйныф укучылары, "Уйлап табучылар" һәм "Яшен" төркемнәренә бүленеп, тапкырлык һәм зирәклектә көчләрен сынашты. Төркемнәр бәйгегә әзерләнгән арада, урта буын сыйныф укучылары үзләренең чыгышларын күрсәтте. Тамашачылардан сайланган жюри җиңүче итеп "Яшен" төркемен билгеләде.



Бәйрәм чаралары бакча төркеме балаларының 31 октябрь көнне үткәргән "Көзге матурлык" дигән чарасы белән тәгәлләнде.



**/ Укучылар иҗаты /**

## *Ямьле Чирмешән буйлары*

Безнең авыл Татарстанның уртасында урнашкан. Авылыбызның кырыеннан бормаланып-бормаланып Чирмешән елгасы ага. Авыл тирәсен суга баетып, кулләре ялтырап ята. Туган ягымның ямьлелеген шушы Чирмешән елгасы , яшел болыннары, әрәмәләре билгели бугай.

Язын ташу вакытын һәрберегезнең күзәткәне бар. Авылдашларның шул чордагы елга тирәсендә шатлыклы аралашуы, бала-чаганың яз килгәнгә сөенүе-авыл кешесенең табигать белән бергә яшәвен исбатлый. Буа тирәсен җәй көне балык тотучылар, яр буйларын су коенучы балалар тагын да җанландыра.

Хәзер авылда көз... Кая күз салма, алтын-сары яфраклы агачлар. Чирмешән елгасын инде ак казлар гына иңли. Тиздән кыш җитәр дә, бөтен җир акка күмелер. Боз өстендә янә балаларның шат авазлары яңгырар.

Барыгызны да алтын көзләр белән! Бер минутка гына тукталып , шул матурлыкны күреп, илебезнең тыныч күген, бәхетле балачагыбызның рәхәтен күреп яшик әле, дуслар...

***Виктория Нукина. VII сыйныф***

## *Яңгыр*

Яңгыр ява, көзге яңгыр,
Ул - киләчәк уңышы.
Әтигә дә ничә еллар
Яңгыр бик күп булышты.

Яңгыр яуса, шатланабыз
Ипи ява, ява байлык.
Кешеләргә, хайваннарга
Бер елга җитте азык.

Яңгыр яуса, җир дә ямьле,
Матур агач-куаклар.
Җиләк- җимеш, яшелчәләр
Ничек итеп тулалар.

Яңгыр ява, көзге яңгыр,
Өметләнә бар кеше
Әтием дә бик шатлана -
Кырда бит аның эше.

***Әминә Туктамышева. VII сыйныф***

**/ Безнең уңышлар /**

## *Батырлар көрәштә сынала*

Узган айда VII сыйныф укучылары, Илдус Камалов белән Ильяс Хабибрахманов, Самара өлкәсендә генерал Сидоровлар призына уздырылган билбау көрәше буенча турнирда үз авырлыкларында беренче урыннарны алып кайттылар.

Сыйныфташлары Зөлфирә белән Әминә батырларыбыздан интервью алып өлгерделәр.

**- Ильяс, көрәш белән ничә яшьтән шөгыльләнә башладың?**



- Ун яшьтән көрәшкә йөри башладым.

**- Бу шөгыль синең үзеңә ошыймы,әллә күбрәк әти-әниең әтәрдеме?**

- Әти-әниләр минем белемле булуымны тели, бу спорт төрен үзем сайладым.

**- Көрәштә кулланган саклану алымнарын тормышта кулланганың бармы?**

- Әйе, сугышып киткән малайларны аерыр өчен кайвакыт кулланырга туры килә.

**- Илдус, узган ярыш синең спорт биографияңдә ничәнчесе булды?**



- Барлыгы 22 ярышта урын алганым булды.

**- Сез җиңү яулаган ярышта кайсы төбәк спортчылары катнашты?**

- Татарстанның ун районыннан килгәннәр иде.

**- Көрәш синең өчен яраткан шөгыльме, әллә булачак һөнәреңме?**

- Яратып көрәшүем һөнәргә әверелсә шат булыр идем.

**Егетләр! Сезне җиңүләрегез белән котлыйбыз! Алдагы еллар сезгә тагын да зуррак уңышлар китерсен! Сез - мәктәпнең горурлыгы!**

**/ Котлыйбыз! /**

Октябрь аенда туган балалар – бакча төркеменнән **Инсаф** белән **Гайшә**, II сыйныфтан **Хәнифә**, III сыйныфтан **Ләйлә** (Нургалиева), V сыйныфтан **Әхмәт** белән **Рияз**, VI сыйныфтан **Кәмилә**, VII сыйныфтан **Данил** белән **Аслан**, VIII сыйныфтан **Халит**! Сезне туган көннәрегез белән чын күңелдән котлыйбыз! Корычтай нык саулык-сәламәтлек, укуда тырышлык, ышанычлы дуслар, күркәм холык телибез! Әти-әниегезгә ярдәмче, туган җиребезгә, милләтебезгә, өммәтебезгә тугры шәхесләр булып үсегез!

**/ Күңелле тәнәфес /**

- Мин инглиз, рус, татар телләрендә иркен сөйләшәм... һәм шулай ук математика, физика һәм географиядә дә.

---

- Марь Иванна, кешегә ул эшләмәгән эш өчен җәза тиешме?
- Юк Вовочка, тиеш түгел.
- Марь Иванна, ә мин өй эшен эшләмәдем!

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Гөлчәчәк Шәмәрданова
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева
Виктория Нукина
Зөлфирә Сафиуллина
Алия Гыйззәтуллина
Нәзирә Әхмәтова
Рузилә Мөхәммәтова
Сара Насыйрова